Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районы
Янил авыл җирлеге Советы

КАРАР

2023 елнын 20 июне № 14

«Җир салымы турында» 2021 елның 29 ноябренәге 32 номерлы Янил авыл җирлеге Советы карарына үзгәреш кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә Янил авыл җирлеге советы карар бирде:

1. «Җир салымы турында» 2021 елның 29 ноябренәге 32 номерлы Янил авыл җирлеге Советы карарына (2022 елның 24 ноябрендэге 33 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2.2 пунктының икенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алыштырырга;

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Җирлек башлыгы: И.Х.Корбанов